**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Наратлы авылы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**2023 елның 20 ноябре,** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авыл җирлегенең Наратлы авылы торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 200 (ике йөз) сум күләмендә гражданнарның үзара салым салуын кертергә.
2. Җыелган акчаны зираттагы ритуаль хезмәтләрне үткәрү өчен йортны төзекләндерүгә юнәлтергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Наратлы авыл җирлеге башлыгы** **С. А. Дмитриев**